Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№3 (30)

Гыйнвар-февраль, 2019 нчы ел

## Бу санда:


| | |
|---|---|
| *Гимназия сулышы* | *1* |
| *Актуаль әңгәмә* | *2* |
| *Ел укытучысы* | *3* |
| *Гимназия Россия чемпионнарын каршы алды* | *4-5* |
| *Әфган - йөрәк ярасы* | *6* |
| *Патриот-шагыйрь Муса Җәлил эзләре буйлап* | *7* |
| *Халыкара Туган тел көне* | *7* |
| *Гимназия яшьләре мәйданчыгы* | *8* |
| *Сәламәт тәндә – сәламәт акыл* | *8* |


## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Ел укытучысы - 2019



Гимназия базасында 8-9 нчы февраль көннәрендә Бөтенроссия “Ел укытучысы” бәйгесенең зона туры үтте. Конкурсантларыбыз ачык дәрес, мастер-класслар күрсәтteләр. Биология укытучысы Ләйсән Фәһимовна Бариева уңышлы чыгыш ясап, республика турына юллама алды. Ләйсән Фәһимовна, уңышлар юлдаш булсын!



### Ел укучысы - 2019

Лицей базасында "Ел укучысы - 2019" конкурсының муниципаль этабы үткәрелде. 4 нче б сыйныф укучылары Әмир Дәүләтшин 2 урын, Наилә Биккинина 3 урынга лаек булдылар. Бәйгедә укучылар интеллектуаль биремнәр эшләделәр, проект эшләре якладылар, шигырь төзү осталыкларын күрсәттеләр.

Укытучылары - Фәхертдинова Ләйсән Әхмәтгаяновна. Котлыйбыз!

### Олимпиада призерларын котлыйбыз

Гимназия укучылары Бөтенроссия олимпиадасының республика этабында яңа үрләр яулады. 9 нчы б сыйныф укучысы Абдуллин Ранэль ОБЖ фәне буенча Бөтенроссия олимпиадасының республика этабында призер (укытучысы - Башаров И.И.), 8 нче б сыйныфы укучысы Зиязова Диләрә исә биология буенча призер, 11 нче б сыйныфы укучысы Фәхертдинова Айгөл экология буенча призер (укытучылары - Бариева Л.Ф.), 7 нче а сыйныф укучысы Шәрифуллина Алсу татар теленнән призер (укытучысы - Авзалова З.З.), 11 нче б сыйныфы укучысы Фәхертдинова Айгөл рус әдәбиятыннан призер (укытучысы - Хәйруллина Ч.А.), 8 нче б сыйныфы укучысы Баянов Шамил призер (укытучысы - Заялова Л.Н.) булдылар.

11 нче б сыйныфы укучысы Фәхертдинова Айгөл мәктәп укучыларының А.М. Терентьев исемендәге XXV Идел буе фәнни экологик конференциясендә 3 нче урынны яулады.

Тырыш хезмәт, белемгә омтылыш шулай югары бәя ала. Чын күңелдән котлыйбыз! Укучыларыбызның уңышлары дәвамлы булсын!







# АКТУАЛЬ ӘҢГӘМӘ

**Район башлыгы Рамил Хәмзә улы Муллин белән 2018 нче ел йомгаклары буенча пресс-конференция үтте, анда узып барган елга нәтиҗәләр ясалды һәм алга бурычлар билгеләнде. Катнашучы укучылар район башлыгына үзләрен кызыксындырган сорауларын бирделәр.**



***Рамил Хәмзович, бу көннәрдә һәркем ел дәвамында башкарган эшләрен барлый. 2018 ел сезнең өчен нәрсәсе белән истәлекле булды һәм бу елга багланган бар өметләр дә акландымы?***

Кайсы гына тармакны алсак та, уңышларыбыз бар. Авыл хуҗалыгы тармагына "Август" компаниясенең керүе отышлы булды һәм без аларның реаль эшләрен күрдек. Ел дәвамында авыл хуҗалыгының төрле тармакларында 2 млрд сумга якын инвестиция ясалды. Техника алу өчен генә 1 млрд сум инвестиция кертелде. Бу безгә тагын да сыйфатлырак эшләргә мөмкинлек бирә.

Узып баручы ел юл төзелеше буенча иң күп инвестицияләр кертелү белән тарих битләренә кереп калыр. Тулаем алганда федераль һәм республика бюджетыннан 600 млн сум акча җәлеп ителде. Тат. Бүләр юнәлешендә аеруча күп эшләнде. Төп юлларны төзү белән бергә, авыл эчләренә дә асфальт юл керде. Объектларны төзекләндерү эшләрен дә дәвам иттек. 2018 елны бик уңышлы булды, дип әйтәсем килә.

***Рамил Хәмзович, 2019 нчы елда нинди үзгәрешләр көтелә?***

Беренчедән, әлбәттә, мөнгән биеклектән төшмәскә.

"Август", "Туган як", "Намус" агрофирмалары, крестьян-фермер хуҗалыклары һәм "Агромастер" җитештерү компаниясе базасында яңа формирование – "Август-агротехнология" компаниясе төзергә ниятлибез. Ул киләчәктә авыл хуҗалыгында дөньякүләм яңа технологияләр нигезендә эшләү өчен бөтен республикага белгечләр әзерләячәк. Бу эшчәнлегебез районны тагын бер баскычка югары күтәрергә мөмкинлек бирер, дип уйлыйм.

"Кояшлы Ык" та республика программасы кысаларында чаңгы базасы, яңа бассейн да төзеләчәк. "Иҗтимагый киңлекләрне төзекләндерү" программасы кысаларында яңа сабантуй мәйданчыгы төзелешен башлау планлаштырыла. Киләчәктә ул 20-30 мең кеше сыярлык зур фестиваль мәйданчыгы булыр, дип көтелә.

2018 елны районда "Сәламәтлек елы" дип игълан итүебезнең максаты изге иде. Бүген бездә сәламәтлегебезне ныгыту, физик яктан чыныгу өчен бөтен мөмкинлекләр бар. "Яшел Мөслим" проекты да рухи тормышыбызны баету, сәламәтлегебезне кайгырту максатында эшләнде. Чөнки утырткан агачларыбыз, бердән, җирлегебезгә матурлык, ямь өстәсә, икенчедән, тын юллары авырулары белән интегүче райондашларыбызга ярдәм итәчәк. Гомумән, безгә сәламәтлегебезне кайгыртып, күңел матурлыгыбызны, рухыбызны баетып, киң күңелле, ярдәмчел булып яшәргә өйрәнергә кирәк.

***Рамил Хәмзович, Сез профессия буенча табиб дип беләбез. Сезне әлеге эшкә нәрсә тартты?***

Мин бала чакта еш чирләдем, шуңа күрә күп вакыт хастаханәдә булырга туры килде. Минем өчен ак халатлы табиблар фәрештә кебек күренделәр. Шулай ук минем әнием дә чирли иде, ләкин ул безгә аны күрсәтмәскә тырышты, шуңа күрә аңа һәрвакыт ярдәм итәсем килде. Абыем (дядя) хатыны белән табиблар, мин аларның гаиләсенә соклана идем. Аларның янына барып, эшләрен күзәтәтергә яраттым. Шушы өч фактор минем киләчәк профессиямне сайлауга тәэсир иткәндер.

***Сезнең кабат-кабат яратып укыган китабыгыз бармы?***

Китапны кабат-кабат укырга вакытым юк, кызганычка каршы, ләкин мин укырга ятатам һәм ешрак укырга тырышам. Күпчелек уз якташларыбыз арасыннан Фоат Садриевның әсәрләрен яратып укыйм. Ул кешенең эчке хис-кичерешләрен тәфсилле итеп сурәтләп яза...

***Рамил Хәмзович, Сез Мөслим районында түгел, ә башка җирлектә район башлыгы булсагыз, шулай ук тырышып, бөтен көчегезне биреп эшләр идегезме?***

Минемчә, кеше нәрсә генә эшләсә дә, эшен төгәл башкарырга тиеш. Мөслим минем туган ягым булганга, мин һәр көн тырышып, аның өчен янып эшлим.

***Рамил Хәмзович, мөһим карарлар кабул иткәндә хезмәттәшләрегез фикеренә таянасызмы? Эш мәсьәләләре турында өйдә дә сөйләшәсезме?***

Өйдә эш хакында сөйләшмәскә тырышабыз. Карарлар кабул иткәндә төрле вакыт була: кайвакытта үз фикереңне туплыйсың да, яңа бурыч-йөкләмә аласың. Күп вакыт шушы түгәрәк өстәл артына урынбасарлар һәм белгечләр белән җыелып киңәшләшәбез, сөйләшәбез. Аларның фикер-тәкъдимнәрен тыңлыйм һәм, уртак бер фикергә килеп, кирәкле карар кабул итүне үз җаваплылыгыма алам. Бүген мин шушы җирлектә башлык икәнмен, мин республика җитәкчелеге алдында, Мөслим халкы алдында җаваплы. Җирлегебездә яшәүче һәр кеше яхшы яшәргә хокуклы. Безнең бурыч – халыкның матур, имин тормышын тәэмин итү.

***Гаиләгездә нинди традицияләр бар?***

Безнең традиция - якшәмбе көнне иртән бергәләп чәй эчү.

***Рамил Хәмзович, әңгәмәгез өчен рәхмәт. Алдагы зур эшләрегездә уңышлар насыйп булсын!***

Җир йөзендә тынычлык, иминлек булуын телим.

*Алинә Ханнанова,*
*Бәдертдинова Динә*

# ЕЛ УКЫТУЧЫСЫ — 2019



8-9 нчы февраль көннәрендә гимназия базасында “Ел укытучысы - 2019” республика конкурсының зона этабы узды. 5 районнан җиңүче укытучылар ике көн дәвамында дәресләр, мастер-класслар күрсәттеләр. Гимназия укытучысы Бариева Л.Ф. уңышлы чыгыш ясады. Дәрес бирүче укытучылар һәм аларны бәяләүче республика эксперт комиссиясе әгъзалары “Мөслим гимназиясе”ндә белем бирүче педагогларның хезмәтенә югары бәя бирделәр һәм укучыларының тирән белемле, тәрбияле балалар булуын билгеләп үттеләр.

10 нчы сыйныфта биология дәресе биргән Түбән Кама шәһәреннән килгән Ирина Владимировна - искиткеч талантлы, компетентлы белгеч, үз фәненең патшасы. Без аның белән дуслашып өлгердек. Дәрестә аңа ярдәм иткән өчен рәхмәтле булуын белдерде:

- Мөслим гимназиясе һәм, гомумән, укучылар, укытучылар, минем күңелемдә бары тик матур хисләр калдырды. Гимназия үзе – җиһазланышы, төзеклеге ягыннан иң яхшы мәктәпләрнең берседер. Мондый мәктәпне мин беренче тапкыр очратам. Сезнең гимназиядә сезнең кебек балалар белән эшләүне зур бәхет дип саныйм.

***Алсу Галиевна, сезгә гимназия укучылары белән дәрес оештыру кыен булмадымы?***

- Мин гимназия директоры Азат Фәритовичка, Лилиана Расиховнага, 8 нче б сыйныфы укучыларына, укытучылары Эльмира Василовнага рәхмәтләремне җиткерәм. Конкурс өчен уңай психологик атмосфера булдырылган, кабинетларда дәрес һәм мастер-класслар уздыру өчен мөмкинлекләр тудырылган, укучылар актив, укытучыны аңлап эшлиләр. Дәресне балалар үзләре алып барды, дисәм дә ялгыш булмас. Укучыларның матур сөйләмгә ия булуы, белемле булулары һәм мөстәкыйль фикерли белүләре аеруча ярдәм итте. Дәреснең беренче мизгеленнән үк укучыларны үз иттем, балаларның теләктәшлеге дәресне уңышлы алып барырга ярдәм итте. Балаларга зур рәхмәт.

Актаныш районы Пучы мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлназ Кәшәфовна белән сөйләштек.

***Гөлназ Кәшәфовна, дәрес ничек булды? Балалар ошадымы? Алар сезнең үз укучыларыгыздан аерыламы?***

- Гимназия укучылары искиткеч тәрбияле, белемле балалар. Минем үземнең укучылардан кайсы ягы белән аерыла дисезме? Мөгаен, креатив фикерләүләре һәм кыю җавап бирүләре беләндер. Нигезле белемле балалар белән эшләве миңа бик җиңел булды.

***Мөслим җирендә үзегезне ничек хис итәсез?***

- Мин Мөслимлеләрнең хезмәт сөючәнлеге турында ишетеп беләм. Бүген моңа тагын бер кат инандым. Мөслим безне бик кунакчыл каршы алды. Гимназия – искиткеч уку йорты. Этажлардан этажларга күчеп, буш вакытта сокланып карап йөрдем, кайбер урыннарны фотога да төшереп алдым. Болар – сезнең җитәкчелекнең балалар турында зур кайгыртуының чагылышы. Шушы гүзәллекнең кадерен белеп, гел “яхшы” билгеләренә генә укыгыз!

Әңгәмәгез өчен рәхмәт! Сезгә уңышлар телибез!

***Конкурсантлар белән Эльгина Мирзаянова сөйләште.***

# КЫШКЫ СПАРТАКИАДА УЕННАРЫ



Укытучыларыбыз спортта да сынатмый. Гимназия командасы XXIX Кышкы спартакиада уеннарында милли көрәш, канат тартышу буенча 1, волейбол, шахмат, бадминтон буенча 2 урыннар яулап, гомуми зачетта 1005 балл белән 2 нче урынга лаек булды. Алдагы этапта да уңышлар телибез! Алга, яңа үрләргә!



# ГИМНАЗИЯ РОССИЯ ЧЕМПИОННАРЫН КАРШЫ АЛДЫ



***Мөслим тарихында беренче тапкыр армрестлинг буенча Россия беренчелегенә ярышларда Илһам Бариев һәм Ислам Гайнуллин 14-15 яшьлек үсмер егетләр арасында чемпион титулына ия булдылар. Чехов шәһәрендә узган Россия беренчелегеннән кайткан спортчыларны һәм аларның тренеры Ларис Хәмбәл улы Бариевны гимназиядә укучы яшьтәшләре каршы алды. Нибары ел-ельярым аралыгында Татарстан чемпионнары, Идел буе федераль округы буенча ярышларда җиңү, ниһаять, Россия чемпионнары титулына ия булу! Күпме бу? Азмы? Танылу өчен күп кирәкме?***

*Спортчылар белән пресс-конференциядән репортаж тәкъдим итәбез.*

***Егетләр, сезне зур җиңүегез белән котлыйбыз. Әңгәмәне ни өчен нәкъ менә шушы спорт төрен сайладыгыз, дигән сораудан башлыйсы килә. Ни өчен армспорт?***

**Илһам:** Армрестлинг – көчле егетләр өчен иң демократик һәм иң гадел спорт төре.

**Ислам:** Миңа кул көрәшенең индивидуаль спорт төре булуы ошый.

***Егетләр, сез үзегезнең нәтиҗәләрегез белән канәгатьме?***

**Икесе бергә:** Әлбәттә.

***Сезнең уңышларыгызга иң нык сөенүчеләр кемнәр булды?***

**Илһам:** әти белән әни, классташлар, укытучылар, дусларыбыз.

***Спортчы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?***

**Ислам:** Минемчә, иң әһәмиятлесе – физик һәм техник яктан әзерлекле булу.

**Илһам:** Әлбәттә, аякның да, кулның да көчле булуы, реакция тизлеге, техниканың камил булуы, шул ук вакытта җиңүгә омтылыш, ныклы характер кирәк.

***Ларис Хәмбалович, егетләрнең уңышка ирешүенең сере нәрсәдә?***

**Ларис Бариев:** Армспорт – чагыштырмача яшь спорт. Бу спорт төре ике төрле юнәлештә бер үк вакытта күп көч куюны таләп итә: беренчедән, физик яктан хәзерлек, икенчедән, камил техникага ия булу. Әзерлекле көндәш секундның бер кечкенә генә мизгелендә синнән өлгеррәк булып чыкса, аның җиңүгә шансы күбрәк дигән сүз. Спортчы егетләребез атнага 5 көн 3-5 сәгать спортзалда яталар, кулга, аяк мускулларын ныгытуга күнегүләр эшлиләр, тимер күтәрәләр, тренажерларда шөгыльләнәләр. Хәтта җәйге каникулларда да тренировкаларны өзмәдек, бары тик июль аенда гына балалар ял итте, ләкин барыбер үзлектән шөгыльләнүләрен дәвам иттеләр. Барлык мускулларны үстерерү өчен нагрузканы дөрес бирергә, нәтиҗәгә әкренләп, этаплап барырга кирәк. Гәүдә тотышы да бик әһәмиятле. Бу егетләргә карасаң, аларны бит баһадир гәүдәле, көчле дип әйтеп булмый кебек. Ләкин алар беренче карашка гына шулай күренәләр. Аларның мускуллары таш кебек каты да, бер үк вакытта бик хәрәкәтчән дә. Бу, әлбәттә, ныклы, эзлекле тренировкалар бәрабәренә ирешелгән нәтиҗәләр.

Гимназия укучылары Илһам Бариев белән Ислам Гайнуллин Татарстан беренчелегенә ярышларда 1 нче һәм 2 нче урыннарны яулап, Татарстан чемпионы титулына ия булдылар. Балтачта районара ярышларда икесе дә беренче урыннарны, ә Ранис Сөләйманов 2, Алмаз Ситдиков 3 нче урыннар яулады. Идел буе федераль округы беренчелегенә ярышларда Илһам 1 нче, Ислам 3 нче, Мөслим урта мәктәбеннән Илнур Кәримов 2 нче урынга лаек булдылар.

Спортчыларга бер җиңү дә җиңел бирелми. Ярышлар сул кул һәм уң кул белән көрәш төрләренә аерыла һәм гомуми зачет буенча чемпионнар билгеләнә. Россия чемпионатына килгәндә, Илһам Бариевка сул кул буенча 14-15 яшьлек үсмер егетләр арасында Россиядә тиңнәр табылмады – алтын медаль һәм чемпион титулына ия булды, гомуми зачет буенча көмеш медаль алды. Ислам Гайнуллин уң кул көрәшендә алтын, сул кул көрәшендә көмеш медаль иясе булды. Бу җиңүләр исә аңа чемпион булу бәхете бүләк итте.

Алга таба үзебезгә яңа максатлар куйдык. Егетләр алдында җитди бурычлар тора. Май аенда Грециядә узачак Европа чемпионатына бүгеннән үк әзерләнәбез.



# ГИМНАЗИЯ РОССИЯ ЧЕМПИОННАРЫН КАРШЫ АЛДЫ

***Сезнең төркемдә күпме бала шөгыльләнә, һәм, гомумән, армспорт Мөслимлеләрне ни дәрәҗәдә кызыксындыра?***

**Ларис Бариев:** Безнең төркемдә 20 ләп укучы йөри. Кайберләре бераз йөри дә ташлый, кайберләре бу төрне үз итеп өлгерде. Күбесе актив шөгыльләнәләр, авырлыклардан курыкмыйлар. Алар арасында өметле спортчылар шактый. Гимназиядән Ранис Сөләйманов, Алмаз Ситдиков, лицейдан Рафгат Әхмәдиев, Илназ Нуруллин, Мөслим урта мәктәбеннән Илнур Кәримов Татарстан егетләре арасында ярышларда үзләрен танытып өлгерделәр. Шул ук вакытта Рафгат Әхмәдиев һәм Илнур Кәримов Россия беренчелегендә уңышлы чыгыш ясадылар. Хәтта кызлар да безнең секциягә язылала, яхшы нәтиҗәләр бирүчеләр дә бар. Лицейда укучы Алия Минкина үз яшьтәшләре арасында Татарстан беренчелегендә һәм Россия беренчелегендә 3 нче урыннар яулады. Форсаттан файдаланып, кызларны да спорт залына чакырам.

***Егетләр, бу спорт төрендә иң авыры нәрсә?***

**Ислам:** Яхшы формада булсаң, авырлык сизелми. Ялкау булмаска кирәк.

**Илһам:** Минемчә, иң авыры - үз-үзеңне җиңү.

***Белгәнебезчә, сез укуда да сынатмыйсыз, спортта да югары нәтиҗәләргә ирешәсез. Сезгә боларның икесен дә тигез алып барырга нәрсә ярдәм итә?***

**Ислам:** Вакытны дөрес бүлсәң, барысына да җитешергә мөмкин.

**Илһам:** Спортчыга укуда түбән өлгерү килешми. Үз алдыңа максат куярга кирәк. Максат булса, уңыш килә.

***Ярышка керер алдыннан җиңәргә булыша торган берәр төрле ритуал башкарасызмы?***

**Ислам:** Бернинди ритуал башкармыйбыз, үз-үзебезгә ышанып керәбез, көндәшебез белән көрәшәбез, стартка басабыз.

***Илһам, әти һәм тренерның бер үк кеше булуы авырлык тудырмыймы?***

**Илһам:** Юк, киресенчә, җайлырак.

***Ларис Хәмбалович, ә сезгә үз балагыз белән эшләү җайлыракмы, әллә чит балалар беләнме?***

**Ларис Бариев:** Үз балам дип, Илһамга аерым җиңеллекләр биргәнем юк. Шунысы уңайлы: улым белән без өйдә буш вакытта да өстәмә эшлибез. Ихатада турникта да күтәреләбез, герләр белән дә эшләп алабыз. Мин чит бала дип әйтмәс идем аларны. Башка гаиләдән булсалар да, спортка мәхәббәт безне якынайтты. Ислам да, башка егетләр дә минем таләпләрне теләп үтиләр. Башкача була да алмый. Спортта иң әһәмиятлесе – дисциплина һәм үз-үзеңне оештыра белү, минемчә.

***Ислам, синең тренерың нинди?***

**Ислам:** Ларис Хәмбалович бик белемле, таләпчән тренер, кешелекле, безнең турыда гел кайгыртып йөри. Аның кул астында без кул көрәшенең барлык алымнарына өйрәнәбез. Ул безгә приемнар гына өйрәтеп калмый, аларның серләрен ача, ярышта үзеңне ничек тотарга киңәшләр бирә. Ул үзе дә бик оста, безгә үрнәк кеше.

***Егетләр, спорт сезнең дөньяга карашыгызны үзгәрттеме? Элеккеге Илһам, Ислам нинди иде? Бүгенге Илһам, Ислам нинди икән?***

**Ислам:** Бүгенге Исламда спортчы характеры, ныклы рухи көч, уңышка ышаныч хисе көчле. Мин элек йомшаграк идем кебек.

**Илһам:** Минем тормышта максатым бар. Элегрәк хоккей, бию белән шөгыльләнгән идем. Хәзер инде мин үзем өчен кирәкле спорт төрен таптым, дип уйлыйм. Әле шул арада шахмат белән дә шөгыльләнәм.



***Ларис Хәмбалович, армрестлинг спорты травма ягыннан ни дәрәҗәдә куркыныч санала?***

**Ларис Бариев:** Әлбәттә, һәр спорт төрендә дә травма куркынычы бар. Гадәттә, ярышка кергәндә балаларның махсус күнегүләр эшләп алуы, бераз мускулларны "җылытып" алуы кирәк. Безнең спорт төрендә тамыр тартылу, сеңер өзелү, бәрелү (ушиб), кул буыннан чыгу, сыну куркынычы бар. Күзәтүләрдән күренгәнчә, физик һәм техник яктан әзерлек дәрәҗәсе түбән булучылар яисә ярышка очраклы рәвештә килеп эләгүчеләр травма ала. Ә микротравмалар – алар гадәти күренеш. Ярыштан соң мускуллар киеренкелеге, буыннарның талчыгуы күзәтелә, организм бераздан кабат торгызыла. Чын спорт шундый инде.

***Егетләр, чемпионнарга карата сыйныфташларыгызның карашы үзгәрдеме?***

**Икесе бергә:** Сизелми. Без бит масаеп йөрмибез.

***Бәлки бу сезнең беренче интервьюдыр. Киләчәктә тагы да дәрәҗәлерәк җирләрдә үз уңышларыгыз турында сөйләргә язсын. Танылган спортсменнар булып, гимназиябез, Мөслимебез, республикабыз горурлыгы булсагыз иде. Уңышлар сезгә, егетләр!***

***Нассер Мәрьям,***
***укучылар үзидарәсе әгъзасы***



# ӘФГАН – ЙӨРӘК ЯРАСЫ



***15 нче февральдә – совет гаскәрләренең Әфганстаннан чыгарылуына 30 ел тулды.***

Вакыт узган саен еллар кочагына сыенып калган "Әфган" сүзе бик күп аналарның җаннарын тетрәндерә, ташкыялар арасында башын салган газиз уллары хакындагы авыр хәтирәләрне яңарта, интернациональ бурычларын үтәп кайткан ир-егетләребезнең яраларын кузгата.

Әфганстан... Ун ел буена барган мәгънәсез сугыш булды бу җирдә. Әфган сугышында барлыгы 546255 совет солдаты һәм офицеры катнашты, шуларның 6669ы гарипләнде, 49985е җәрәхәтләнде, 312се хәбәрсез югалды, 18е чит илләрдә калды, 13833е үлде. Әле тормышның ямен-тәмен дә татып карамаган асыл ир-егетләребезнең гәүдәләре цинк табутларда кайтты.

Үлгәннәр арасында 442 кеше татар милләтеннән. 72 сугышчыга Советлар Союзы Герое исеме бирелде.

Әфган сугышында Татарстан Республикасыннан 9570 кеше катнашты, 256 сугышчы һәлак булды, 233е инвалид, 546сы яраланды һәм контузия алды. Шуның 132се татар.

1989 елның 15 февралендә соңгы совет солдаты Әфган чиген атлап чыкты. Ләкин әле бу аяусыз сугыш безнең өчен тәмамланмады. Чөнки аналарның күз яшьләре бүгенгәчә кипми, ә йөрәкләрендәге яра гомер буе төзәлә алмаячак.

Әфган сугышы тәмамлануга 30 ел тулган истәлекле көндә үзебезнең гимназиядә уллары һәм кызлары белем алган әтиләребезне – Әфган сугышы ветераннарын чакырдык.

Бүгенге көндә Мөслим районның сугышчы-интернационалистлар иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Данил Госманов, Зиннур Галиев, Маис Шәрипов, Ринат Харрасов, Алмаз Мирзаянов, Алмаз Солтанов, Нияз Хәйбрахманов, Дамир Шәфигуллин укучыларга тарихта калган утлы еллар, Әфганстанда узган яшьлек еллары турында истәлекләр сөйләделәр. Әмәкәй авылы егете Илфар Фәрраховның энесе Мансур безнең гимназиядә укый. Аның белән бергә абыйсыннан килгән солдат хатларын укыдык. Ветераннар дулкынлану хисе белән сөйләделәр. Чыгышларны тыңлаганда барыбыз да аларның "намус", "хәрби бурыч" төшенчәләрен үз тормышыннан да өстенрәк куйганнарын аңлап утырдык.

Зур сугышлар бетә, ә тарих мәңгелек. Әфган сугышы да тарихыбызга кереп калды. Еллар үткән саен, йөрәкләребезне телгәләп, искә төшереп торачак авазлар калды: җан, тән яралары алып кайткан исәннәр, мәңгелек ятып калган солдатларның җырлары калды. Данил абый Госманов башкаруында җыр барыбызның да нәни йөрәкләренә үтеп керде.



Солдат сугышны сайламый. Ул сугышны игълан да итми. Ул бары тик биргән антына һәм хәрби бурычына тугрылыклы булып, Халык һәм Ватан исеменнән бирелгән боерыкны гына үти. Аның каһарманлыгы, батырлыгы, Ватанга ихтирамы һәм мәхәббәте нәкъ менә шунда күренә.

Бүген безнең арада булган хөрмәтле ветераннарыбызга эчтәлекле чыгышлары өчен рәхмәт белдерәбез. Сәламәт булыгыз! Дөньялар тыныч, күгебез аяз булсын!

***Әдилә Бәдертдинова,***
***6 нчы а сыйныфы укучысы***

## Батырлык урыны - Әфганстан



Шириев Илгиз

Ун елга сузылган Әфган сугышы. 18-20 яшьлек егетләрнең гомерләрен өзгән сугыш тукталганга 30 ел.

Безнең районыбыздан сугышта 6 ир-егетебезнең гомере өзелгән. Сугыштан исән-сау кайтканнарның да күбесе якты дөньяда юк инде. Алар арасында минем әтием - Шириев Илгиз дә бар.

Әфганстанның Кабул шәһәрендә урнашкан хәрби частьта хезмәт итә ул. КамАЗ машинасы белән йөк ташый. Бергә хезмәт иткән иптәшләренең үлемен күп күрергә туры килә.

Райондашыбыз Кызыл Йолдыз ордены кавалеры Маис абый Шәрипов белән бер полкта хезмәт итә әтием. Кайтырга приказ чыккач та, бер ай хезмәт итәргә туры килә аңа. Вакытвакыт бу мәгънәсез сугыш турында сөйләп ала иде ул. Әтием сугышта зур батырлыклар кылмаган, әмма 2 ел үлем белән күзгә-күз очрашкан. Рәхмәт хатлары һәм медальләре Салауз Мухан тәп гомуми белем бирү мәктәбе музеенда саклана. Аларны карап узганда, мин аерым бер горурлык хисе тоям. Минем әтиемнеке бит алар!

Еллар узу белән йөрәк яралары төзәлсә дә, тән яралары төзәлми шул. 45 яшендә әтиебез безне мәңгелеккә калдырып китте.

Әтиемне сагынганда, апаларым, абыем һәм әнием белән бергәләшеп аның янына барабыз.

***Айсылу Шириева,***
***5 нче б сыйныфы укучысы***

## ПАТРИОТ-ШАГЫЙРЬ МУСА ҖӘЛИЛ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

15 нче февраль – патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең туган көне. Гимназиядә һәр елны Муса Җәлил иҗатын, кабатланмас батырлыгын өйрәнү максатыннан төрле чаралар оештырыла. 7а-7б сыйныфлары арасында узган “Йолдыз сәгате” (Авзалова З.З.), башлангыч сыйныфлар арасында шигырь укучылар конкурсы (Солтанова Г.М.), барлык классларда узган тәрбия сәгатьләре шул турда сөйли. “Җәлил эзләре буйлап” дип аталган әдәби-музыкаль информацион-лингвистик квест-уенда 5-6 нчы сыйныф укучылары көч сынашты. 6 тукталышта төрле биремнәрне уңышлы үтәп, 5 нче а сыйныфы җиңүгә иреште. Квест-уенны 10 нчы в сыйныфы укучылары әзерләде.

***Камилла Шакирова,***
***10 нчы в сыйныфы укучысы***






## 21 НЧЕ ФЕВРАЛЬ – ХАЛЫКАРА ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ

***Берләшкән Милләтләр оешмасы карары буенча 21 нче февраль Халыкара туган тел көне буларак билгеләп үтелә.***

1999 нчы елның ноябрендә, Бангладеш дәүләте тәкъдиме белән, ЮНЕСКО Генераль конференциясе, ЮНЕСКОга кергән илләр һәм Берләшкән Милләтләр оешмасы 21 февраль көнен Туган тел көне дип игълан итте. Беренче мәртәбә ул 2000 елның 21 нче февралендә Парижда ЮНЕСКО штаб-квартирасында тантаналы рәвештә билгеләп үтелде.

Ни өчен Халыкара туган тел көне итеп 21 февраль билгеләнгән соң? Эш шунда: 1952 елның 21 нче февралендә Пакыстанда бенгалы теленә дәүләт теле статусы таләп итеп көрәшкән 5 студент үтерелгән була. Билгеле булганча, Пакыстанның көнчыгыш өлеше соңрак Бангладеш бәйсез дәүләтенә әйләнә.

ЮНЕСКО Халыкара туган тел көнен билгеләп үтүне хуплап чыга. Чөнки бу оешма дөнья халыкларының матди булмаган мирасын саклау өчен көрәшә, традицион яисә халык музыкасын, биюләрен, гореф-гадәт һәм йолаларны, авыз иҗатын һәм җирле халыкларның туган телләрен саклап калу буенча зур эшчәнлек алып бара.

Җир йөзендә бүгенге көндә 6000 тел бар дип исәпләнә. Шулардан иң күп санлы кешеләр тарафыннан кулланыла торганы — кытай теле, бу телдә 1,2 млрд кеше сөйләшә, инглиз телендә — 478 млн, хинди телендә — 437 млн, испанда — 392 млн, рус телендә — 284 млн, гарәптә — 225 млн, португалда — 184 млн, француз телендә 125 млн кеше сөйләшә.

Таралыш тыгызлыгы ягыннан мондый саннарны китерергә мөмкин: 6000 телнең яртысы Азия-Тын Океан регионында кулланыла. Яңа Гвинея төбәгеннән исә 1000 тел чыккан дип санала.

Белгечләр якындагы йөзьеллыкта барлык телләрнең 95% ы яшәүдән туктар дип фараз итә. Мәсәлән, бер ел эчендә 10 тел юкка чыга дигән фикер бар. Тел ягыннан аеруча чуар булган төбәкләрдә телләрнең юкка чыгуы бигрәк тә көчле. Африкада биш йөздән кимрәк кеше сөйләшә торган 200 тел барлыгы билгеле, Америка Кушма Штатларында һәм Канадада индеецларның 200 теле юкка чыгу алдында тора дип саныйлар. Бу процесслар аеруча Бразилиядә көчле. Көньяк-Көнчыгыш Азиядә 600-700 тел бар, шуларның кырыгы дәүләт ярдәменә мохтаҗ.

Европа илләрендә 123 телдән тугызы юкка чыккан, егерме алтысы югалу алдында тора, тагын 38 телгә шундый ук куркыныч яный.

Күргәнебезчә, дөньяда бик күп телләргә бетү куркынычы яный. Тел юкка чыктымы, шул телдә сөйләшкән халык та юкка чыга дигән сүз, чөнки ул инде башка телдә сөйләшә башлый, шул телдәге мәгълүматны үзләштерә, ә аның үз бабаларының йөзләрчә ел үсеп-формалашып килгән мәдәнияты тел белән бергә юкка чыга.

*Гимназиядә Халыкара Туган тел көненә багышланган квест-уен оештырылды. Татар, рус, инглиз телендә биремнәрне 10 нчы в сыйныфы укучылары үзебез әзерләдек.*




*Волонтерлар командаларны алдан әзерләделәр һәм уен барышында аларга җитәкчелек иттеләр. 6-8 нче сыйныфлар арасында 6 нчы а һәм 8 нче б сыйныфы укучылары интеллектуаль яктан аерылып тордылар. Мондый чаралар укучыларны бер максатка берләштерә, дип саныйм. Төрле рольләрдә үзебезне сынап карау мөмкинлеге булу барыбызга да ошый. Безнең үзебездә дә активлык, креативлык арта, оештыру сәләтебез үсә.*

***Ксения Петрова,***
***10 нчы в сыйныфы укучысы***

## ГИМНАЗИЯ ЯШЬЛӘРЕ МӘЙДАНЧЫГЫ

### Заман яшьләре. Вакыйгалар. Фактлар



Соңгы вакытта яшьләр арасында өлкәннәргә аңлашылмый торган сүзләр белән аралашу күзәтелә. Гимназия психологы А.Т.Кәримова белән шул хакта әңгәмә тәкъдим итәбез.

***Айсылу Тәлгатовна, интернетта яшьләрнең сленг белән аралашу күренеше безнең укучылар арасында да кереп бара түгелме? Бу проблема турында чаң сугарга кирәкме?***

- Яшьлек – ул эзләнүләр чоры, яшьләрнең мөмкин кадәр күбрәк мөстәкыйльлек яулап алу вакыты. Үз-үзен эзләү чорында үсмер бала төрле шаукымнарга, модалы агымнарга иярә, төркемнән кайсыдыр ягы белән аерылып торырга омтыла, шулай итеп үз "мин"ен табарга тырыша. Киенү стиле, атлап йөрү, төрле музыкалар белән мавыгу, үзенчәлекле сөйләм, аңлашылмый торган лексика - шул күренешнең билгеләре. Гадәттә, болар – вакытлы күренеш. Яшүсмер үзенең гамәлләре өчен җаваплы икәнен әле акылы белән аңлап бетерми. Соңрак, чын-чынлап "өлгереп" җиткәч, мондый мәсьәләләргә бала җитди карый башлый. Ата-ана, укытучы баладагы үзгәрешләрне күзәтергә, вакытында күрә белергә тиеш. Әгәр баланың лексикасы ситуатив характерда гына сленглар куллануга корылса, монда бернинди куркыныч юк. Сөйләм тулысы белән сленглардан гына тора икән, борчылырга җирлек бар дигән сүз. Педагогка гаилә белән элемтәгә керергә, дусларын ачыкларга тәкъдим итәлә.

***Ата-аналарга бу мәсьәләдә нинди киңәш бирер идегез?***

- Беренче чиратта, әлбәттә, гаиләдә сабый вакыттан ук балада зәвык тәрбияләргә, эчтәлекле китаплар, мәгънәле фильмнар карарга күнектерергә кирәк. Гаиләдә аралашу теле үз туган телебездә булса, өлкәннәр һәм балалар арасында үзара хөрмәткә нигезләнгән матур мөнәсәбәтләр булса, бала үз телен чүпләү, сленглар белән чуарлау ягында булмас, минемчә. Баланың интеллекты гаиләдә формалаша. Аның сөйләменә бик кечкенә вакыттан ук игътибарлы булырга, сүзләрнең синонимнары белән сөйләшергә, тупас сүзләрдән телне арындырырга күнектерергә кирәк. Р.Фәхреддин әйткәнчә, бала вакытта алган тәрбияне бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас. Баланың үз теленә сак каравы төркемдә аерылып тору теләгеннән көчлерәк булса, яшүсмерләргә хас проблемалар да җиңел узачак.

**PS:** Язманың ахырында үзебезнең укучылар арасында кулланылган сленглардан торган сүзлек тәкъдим итәбез:

**Ку(q)** - сәламләү сүзе

**Хайп** – популярлык, шумиха, ажиотаж

**Швепс** – әр-яңа, супер

**Чуитс** – универсаль сүз: сәлам, яхшы, пока дигән мәгънәләрдә йөри

**Свэг** – текә (круто)

**Лук** – кием

**Мем** – кызык шаярту

**Баян** – искелек, кызык түгел, яңалык түгел

**Хейтер** – дус түгел (берәрсе сиңа ошамаган коммент язса әйтелә)

**Чилить** – берни эшләмичә ялкауларча ял иту

**Изи** – җип-җиңел (легко, просто)

**Зашквар** – оят, бред, модалы түгел

**Свайп** – сенсор экранда бармак белән йөрү

**Жиза** – "такова жизнь" фразасы урынына кулланыла

Әлбәттә, без бу сүзләрне актив лексикага кертү ягында түгел. Шулай булса да, дөньякүләм барган бүгенге процесслардан без бөтенләй азат түгел. Гимназия укучыларын үз туган телебез сагына басарга чакырабыз. Төрле шаукымнарга ияреп, гомумән телсез, туган илсез калмыйк. Телебез язмышы да, милләтебез язмышы да, матур киләчәгебез дә үз кулыбызда.

***Әңгәмәне Айгөл Сабитова әзерләде.***

## СӘЛАМӘТ ТӘНДӘ – СӘЛАМӘТ АКЫЛ



Йөзү ярышлары




Чаңгы юлы



Афәрин, егетләр!

ТЫЛСЫМ+
Гыйнвар-февраль, 2019 нчы ел
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Ханнанова Алинә
**Корректорлар:** Сабитова Айгөл, Әхмәтҗанов Булат
**Корреспондентлар:** Бәдертдинова Әдилә, Нассер Мәрьям
**Дизайнер:** Харитонов Динар
**Компьютерда җыючылар:** Бәдертдинова Динә, Мирзаянова Ильгина
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru